СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail:alanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**25 июнь 2019 ел** **№ 172**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 сентябрендәге 149 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2019 елның 01 маендагы 87-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 сентябрендәге 149 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;».

2) 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар җыены торак пунктта яисә җирлектә сайлау хокукына ия булган яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда, узган дип санала. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысы берьюлы бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән Алан-Бәксәр авыл җирлеге уставы нигезендә, гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакытта, этаплап уздырыла. Шул ук вакытта, гражданнар җыенының алдагы этапларында катнашкан затлар аннан соңгы этапларда тавыш бирүдә катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ да урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Башкаруны тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина